**Карар № 33**

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Югары Сәрдә авыл җирлеге Советы утырышы**

Югары Сәрдә 06.12.2021ел

**Югары Сәрдә авыл җирлеге Советының 2019 елның 11 ноябрендәге 110 номерлы карары белән расланган “Югары Сәрдә авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмә”гә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр керүне һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдән чыгуын исәпкә алып, Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге Советы карар кылды:

1. Югары Сәрдә авыл җирлеге Советының 2019 елның 11 ноябрендәге 111 номерлы карары белән расланган «Югары Сәрдә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмә”гә кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

2. Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының http://atnya.tatarstan.ru/ рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында игълан итәргә.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә халыкка җиткерелгәннән соң үз көченә керә.

3.1. Кararга кушымтаның 1 пункты 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Әтнә муниципаль районы
Югары Сәрдә авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Хөснетдинов

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге Советының 2021 елның 06 декабрендәге 33 нче номерлы карарына кушымта

**2019 елның 11 ноябрендәге 110 номерлы Югары Сәрдә авыл җирлеге Советы карары белән расланган «Югары Сәрдә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмә”гә үзгәрешләр һәм өстәмәләр.**

**1. 32 статьяның 2 өлешендәге 2 Абзац**:

а) түбәндәге эчтәлекле икенче абзацны өстәргә:

"- Россия Федерациясе Милли үсешенең максатларын һәм аларга ирешү буенча ачык хакимият органнары эшчәнлегенең юнәлешләрен билгели торган документлар;";

б) икенче - дүртенче абзацларны өченче - бишенче абзацлар дип санарга;

**2. 27 статьяның 27 пунктын түбәндәгечә тулыландырырга:**

"Кредит (займ) буенча принципал йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итә торган муниципаль гарантия кредит килешүендә (займ килешүендә) һәм (яисә) күрсәтелгән муниципаль гарантияне кредитор (заемчы) йөкләмәләрен бирү турындагы шартнамәдә үз ягыннан күрсәтелгән кредит (займ) акчаларын максатчан файдалануны тикшереп тору шарты белән бирелә.";